| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МОЛВИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>МУЛЛА ИЛЕ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

07 июль 2026 ел Мулла Иле ав. **№ 39**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мулла Иле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 24 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә техник хаталарны бетерү максатларында Мулла Иле авыл җирлеге Советы:

1.Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мулла Иле авыл җирлеге Советының 2026 елның 11 июнендәге 35 номерлы карары белән расланган Мулла Иле авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә (Мулла Иле авыл җирлеге Советы карарлары15.06.2026 елгы 37 номерлы үзгәрешләр кертеп) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. 5 статьяның 6 өлешендә «статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында» сүзләрен «әлеге статьяның 1 өлешендәге 2 пунктында»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. 8 статьяның 1 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Депутат эшчәнлеге рәвешләре булып:

1) җирлек Советы сессияләре эшендә катнашу;

2) җирлек Советының даими комиссияләре эшендә катнашу;

3) федераль дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының вазыйфаи

затларына, барлык оештыру-хокукый рәвештәге оешма җитәкчеләренә, иҗтимагый берләшмәләргә мөрәҗәгать;

4) муниципаль хокукый акт проектын кертү;

5) җирлек Советы тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актлар проектларын эшләүдә катнашу;

6) җирлек Советы тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына закон чыгару инициативасы тәртибендә кертелә торган Татарстан Республикасы законнары проектларын әзерләүдә катнашу;

7) депутат гарызнамәсе кертү;

8) сайлаучылар белән очрашулар, аларның мөрәҗәгатьләре белән эшләү, үзе вәкил булган җирлек халкына үз эшчәнлеге һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү;

9) җирле референдумнарны, гавами тыңлауларны, җыелышларны, конференцияләрне һәм гражданнардан сорашып белешүләрне оештыруда һәм уздыруда катнашу;

10) территориаль иҗтимагый үзидарә оештыруда катнашу.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет " мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Мулла Иле, Яңа ур., 3 нче йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мулла Иле, Үзәк ур., 17а йорт (мәдәният йорты бинасы)

Мулла Иле авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе И.Г.Сәлахиев